| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>НУРЛАТСКОГО СЕЛЬСКОГО<br>ПОСЕЛЕНИЯ ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>НОРЛАТ ҖИРЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**15.06.2023ел** Норлат ав. **№119**

Җирле салымнар суммалары өлешендә бурычларны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында.

Зеленодольск муниципаль районы Норлат авыл җирлеге башлыгы И. М. Саттаровның җирле салымнар суммасы буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турындагы мәгълүматын тыңлап һәм фикер алышып, Россия Федерациясе Салым кодексының 59 статьясының 3 пункты, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Норлат авыл җирлеге»муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Норлат авыл җирлеге Советы **карар итте:**

1. Җирле салымнар суммалары буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләргә:

1.1. физик затның үлеменнән соң өч еллык срокның тәмамлануы яки аны гражданлык процессуаль законнары нигезендә билгеләнгән тәртиптә үлгән дип игълан ителүе, әгәр дә закон буенча да, васыять буенча да варислар юк икән, яки варисларның берсе дә варис булырга хокуклы түгел, яки барлык варислар да мирас алудан читләштерелгән, яки варисларның барысы да мирас алудан баш тарткан, һәм аларның берсе дә башка варис файдасына баш тартуын күрсәтмәгән;

1.2. салым салу объекты булган милеккә милек хокукы туктатылган көннән алып өч еллык срокның тәмамлануы;

1.3.җирле салымнарны һәм җыемнарны түләү буенча бурыч барлыкка килгән көннән алып өч еллык срок тәмамлану.

2. Зеленодольск муниципаль районы Норлат авыл җирлеге Советының «Җирле салымнар буенча бурычларны, пенялар һәм штрафлар буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләре турында» 2022 елның 05 декабрендәге 89 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматларының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының рәсми сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) Интернет мәгълүмат-телекоммуникация

челтәрендә, шулай ук Норлат авыл җирлегенең мәгълүмати стендларында: Татарстан Республикасы, Зеленодольск  муниципаль районы, Норлат авылы, Гагарин урамы, 46 йорт (поселение администрациясе бинасы), Норлат авылы, М.Фәйзуллин урамы, 17 йорт («Волга аръягы»ЦКС бинасы) урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыккач үз көченә керә һәм 2023 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә үз көчен җәелдерә.

**Норлат авыл җирлеге башлыгы,**
**Совет рәисе** **И.М.Саттаров**